РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2024 Буа шәһәре № 361 Бк/к

Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 12 һәм 15 статьяларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак биналарны һәм гомуми мөлкәтне җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче торак урыннарына карата инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын җайлаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү турында» 958 номерлы карарына ярашлы рәвештә, ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалидлар өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү чаралары планын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 05 февралендәге 18/Бк/к номерлы «Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда

инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составын һәм эш тәртибен раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар имза салынган көненнән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән басылып чыгарга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

2 нче кушымта

Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составы

| | |
|---|---|
| Хәмидуллин Р.Р. | Буа муниципаль районы Башкарма комитетының беренче урынбасары, комиссия рәисе; |
| Садретдинова Л.Н. | Буа муниципаль районы Башкарма комитеты урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Гомщрова Э.И. | Буа муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия секретаре; |
| Сафин А.М. | Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, (килешү буенча); |
| Гыйлфанов Р.М. | Буа муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы; |
| Идиятова Л.С. | «УК-Буинск» ҖЧҖ генераль директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча); |
| Зәйнуллин М.А. | «Западный» торак милекчеләре ширкәте рәисе (килешү буенча); |
| Камалова Л.Р. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Буа муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Горелова А.А. | «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы» – «Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте»иҗтимагый оешмасының Буа районы оешмасы рәисе |

1 нче кушымта

Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалидлар өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү чаралары планы

| № т/б | Чара | Чараны үтәү срогы | Җаваплы һәм башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссиягә инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалидларның алардан файдалана алу шартларын тәэмин итү максатларында муниципаль милектәге торак урыннар исемлеген әзерләү һәм аларны тикшерү буенча муниципаль комиссиягә җибәрү | Апрель 2025 ел | Буа шәһәре Башкарма комитеты |
| 2. | Инвалидлар исемлеген әзерләү һәм муниципаль комиссиягә җибәрү | Апрель 2025 ел | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Буа муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге |
| 3. | Әлеге планның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән документларны карау һәм Буа муниципаль районының торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннары һәм гомуми мөлкәт реестрын төзү | Май 2025ел | Муниципаль комиссия |
| 4. | Утырышны тикшерү (йомгаклар) графигы буенча фикер алышып үткәрү һәм муниципаль комиссия эше буенча тәкъдимнәр әзерләү | квартал саен | Муниципаль комиссия |
| 5. | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынына, гомуми мөлкәткә өстәмә тикшерүләр, торак бинаның таяныч конструкцияләрен сынау кирәк булганда визуаль, техник тикшерү үткәрү;<br>торак урында яшәүче инвалид дип танылган граждан белән әлеге гражданның торак | Май-июнь 2025ел | Муниципаль комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | урынны җайлаштыруга карата конкрет ихтыяҗларын ачыклау максатларында әңгәмә үткәрү;<br>инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми мөлкәтне инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү кирәклеген һәм мөмкинлекләрен ачыклау. | | |
| 6. | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми мөлкәтне инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү максатларында тикшерү актын (алга таба – тикшерү акты)әзерләү | 3 ай дәвамында | Муниципаль комиссия |
| 7. | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм (яисә) гомуми мөлкәтне инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү максатларында күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) реконструкцияләүнең яисә капиталь ремонтлауның икътисадый максатка ярашлылыгын тикшерү турында карар кабул итү, әгәр тикшерү актында мөмкин түгеллеге турында нәтиҗә булса инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урыны һәм (яисә) гомуми мөлкәт җайланмалары, инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итүне исәпкә алып күпфатирлы йортның (йортның бер өлешенең) гамәлдәге таяныч һәм киртәләү конструкцияләрен реконструкцияләү яисә капиталь ремонтлау юлы белән үзгәртмичә) | Тикшерү акты төзелгән көннән алып 3 ай эчендә | Муниципаль комиссия |
| 8. | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм (яисә) гомуми мөлкәтне инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү максатларында күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) мондый реконструкцияләүнең яисә капиталь ремонтлауның икътисадый максатка ярашлылыгын тикшерү | Тикшерү акты төзелгән көннән алып 3 ай эчендә | Муниципаль комиссия |
| 9. | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм (яисә) инвалидның гомуми мөлкәтен инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү максатларында инвалид яши торган күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) реконструкцияләүнең яисә капиталь | Тикшерү акты төзелгән көннән алып 5 ай эчендә | Муниципаль комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ремонтлауның икътисадый максатка ярашлылыгы яисә максатка ярашсызлыгы турында карар кабул итү. | | |
| 10. | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми мөлкәтен инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итү мөмкинлеге турында бәяләмә яисә мондый мөмкинлекнең булмавы турында бәяләмә кабул итү һәм күрсәтелгән Бәяләмәне Татарстан Республикасы төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрү | Тикшерү акты төзелгән көннән алып 5 ай эчендә | Муниципаль комиссия |